| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ БОЛЬШЕШИНАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ШЫҢАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|
| 422054, Республика Татарстан, Сабинский район,<br>с.Большой Шинар, ул. Кооперативная, 36<br>тел. (84362) 41-2-11 | 422054, Татарстан Республикасы, Саба районы,<br>Олы Шыңар авылы, Кооператив урамы, 36 йорт<br>тел. (84362) 41-2-11 |

e-mail: bshin.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР
24.09.2018 № 22

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлегендә гражданнардан үзара салым акчасы җыю һәм аны куллану буенча җирле референдум билгеләү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре турында” 12.06.2002 №67-ФЗ Федераль законның 15 нче статьясына, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның төп принциплары турында” 06.10.2003 №131-ФЗ Федераль законның 22.56 статьялары, Татарстан Республикасының “Җирле референдум турында” 24.03.2004 №23-ЗРТ 18 статьясы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясына туры китереп, Олы Шыңар авыл җирлеге Советының 17.09.2018 №18 “Референдум уздыру инициативасы турында” карары, Олы Шыңар авыл җирлеге башкарма комитетының 17.09.2018 №21-п “Референдум уздыру инициативасы турында” карары нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлегендә гражданнардан үзара салым акчасы җыю соравын кертү буенча җирле референдумны 2018 елның 18 ноябренә билгеләргә.

2. Җирле референдумга куеласы сорауларны түбәндәгечә расларга:

“Сез яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Олы Шыңар авыл җирлеге биләмәсендә теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 2019 елда 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм аны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы:

- Олы Шыңар авылында җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү;
- Кече Шыңар авылында җирле әһәмияттәге юлларны тозекләндерү;
- Оет авылында җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү;
- Чулпыч авылында җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү;

ӘЙЕ ЮК”

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында бастырырга.

4. Карар басылып чыккан (халыкка хәбәр ителгән) көннән соң үз көченә керә.

Олы Шыңар авыл җирлеге башлыгы А.Г.Гарипов